**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 4-40 номерлы карары**

## Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 26 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82, 83, 84 статьялары нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәре Думасының 2006 елның 8 июнендәге 5-9 номерлы, 2007 елның 16 августындагы 7-19 номерлы, 2008 елның 26 июнендәге 15-31 номерлы, 2009 елның 29 апрелендәге 16-40 номерлы, 2010 елның 10 мартындагы 11-48 номерлы, 2010 елның 8 октябрендәге 2-54 номерлы, 2010 елның 6 декабрендәге 13-2 номерлы, 2011 елның 24 октябрендәге 14-8 номерлы, 2012 елның 19 апрелендәге 9-13 номерлы, 2013 елның 13 февралендәге 15-20 номерлы, 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 16-34 номерлы, 2015 елның 4 мартындагы 30-41 номерлы, 2015 елның 7 сентябрендәге 13-45 номерлы, 2016 елның 20 апрелендәге 16-6 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 43-13 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 7-20 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 21-25 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 16-30 номерлы, 2019 елның 18 апрелендәге 14-33 номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 14-38 номерлы, 2020 елның 21 октябрендәге 8-2 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 4-7 номерлы, 2022 елның 15 апрелендәге 18-13 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 17-18 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 4-23 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге

21-29 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 5-31 номерлы, 2025 елның 20 февралендәге 8-36 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү өчен юлларга.

3. Әлеге карарны, дәүләт тарафыннан теркәгәннән соң, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 56 статьясындагы 9 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарга кушымтаның 10 пунктындагы бишенче абзацы Казан шәһәре Думасы рәисе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Казан шәһәре Мэрына карата 2027 елның 1 гыйнварына кадәр сайланган Казан шәһәре Думасының вәкаләтләре чоры тәмамланганчы гамәлдә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарга кушымтаның 10 пунктында билгеләнгән Казан шәһәре Мэрын сайлау тәртибе әлеге карар үз көченә кергәннән соң сайланган Казан шәһәре Мэрына карата кулланыла дип билгеләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 12 августындагы
4-40 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяның 2 өлешендә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. 12 статьяда дүртенчедән алып алтынчыга кадәр абзацларны төшереп калдырырга.

3. 15 - 17 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. 18 статьяның 2 өлешендә «күпфатирлы торак йорт подъезды;» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. 19 статьяның 4 өлешендә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 28 статьясындагы 5 өлеше белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 47 статьясындагы 10 өлеше» сүзләренә алмаштырырга.

6. 21 статьяда:

6.1. 2 өлештә «уналты яшькә» сүзләрен «унсигез яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

6.2. 3 өлешнең 3 пунктында «уналты яшькә җиткән» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. 26 статьяда:

7.1. 8.1 өлештә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне

оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

7.2. 8.2 өлештә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

8. 28 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, Шәһәр Думасының муниципаль берәмлек территориясендә үтәлүе мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган, шулай ук Шәһәр Думасы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Шәһәр Думасы карарлары Шәһәр Думасы депутатларының билгеләнгән санныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә».

9. 32 статьяда:

9.1. 1 өлешнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законда каралган тәртиптә һәм нигезләр буенча Шәһәр Думасын тарату»;

9.2. 1 өлешнең бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 12 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган Казан шәһәрен үзгәртеп кору»;

9.3. 3 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«14) 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бүтән очракларда»;

9.4. 3.1 өлештә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне

оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

10. 33 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«33 статья. Муниципаль берәмлек башлыгын – Казан шәһәре Мэрын сайлау.

1. Казан шәһәре Мэры Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан Шәһәр Думасы Регламентында билгеләнгән тәртиптә яшерен тавыш бирү юлы белән Шәһәр Думасы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән Шәһәр Думасы тарафыннан сайлана.

2. Казан шәһәре Мэры вазифасына керешү тантаналы шартларда Казан шәһәре Мэрына Казан шәһәре Мэры вазифаи билгесен тапшыру белән Шәһәр Думасы утырышында башкарыла.

3. Шәһәр Думасы депутаты булып торган сайланган Казан шәһәре Мэры Шәһәр Думасы рәисе вәкаләтләрен башкара.

4. Казан шәһәре Мэрының вәкаләтләр чоры биш ел тәшкил итә».

11. 34 статьяның 4.1 өлешендә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

12. 34.1 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Казан шәһәре Мэры беренче урынбасар, ике урынбасар һәм Казан шәһәре Думасы секретаре булдырырга хокуклы. Алар Казан шәһәре Мэры тәкъдиме буенча ачык тавыш бирү юлы белән Шәһәр Думасы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш белән сайлана».

13. 37 статьяда:

13.1. 2 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Казан шәһәре Мэрының вәкаләтләре 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 21 статьясындагы 1 өлешендә һәм 30 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла»;

13.2. 2.1 өлешне төшереп калдырырга.

14. 43 статьяның 5 өлешендә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы белән» сүзләрен

«2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга.

15. 45 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«45 статья. Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы

1. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләре 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 23 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла».

16. 78 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 21 статьясындагы 22 өлешендә һәм 23 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракларда, Татарстан Республикасы Рәисе Казан шәһәре Мэрын яисә Башкарма комитет Җитәкчесен вазифасыннан азат итү турында хокукый акт чыгара».

17. 78.1 статьяда:

17.1. 1 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Шәһәр Думасы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль закон нигезендә Казан шәһәре Мэрын Шәһәр Думасы депутатлары инициативасы буенча яисә Татарстан Республикасы Рәисе инициативасы буенча отставкага җибәрергә хокуклы»;

17.2. 2 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Казан шәһәре Мэрын отставкага чыгару өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) Казан шәһәре Мэрының 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 38 статьясындагы 1 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында каралган нәтиҗәләргә китергән карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы)»;

2) 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законда, башка федераль законнарда, әлеге Уставта каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру

бурычларын һәм (яисә) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын өч ай һәм аннан да күбрәк вакыт эчендә үтәмәү;

3) Казан шәһәре Мэрының Шәһәр Думасы алдындагы еллык хисабы нәтиҗәләре буенча ике тапкыр рәттән бирелгән эшчәнлегенә Шәһәр Думасының канәгатьләнерлек бәя бирмәве;

4) 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 28 статьясындагы 5 өлеше нигезендә муниципаль вазифаларны биләүче затлар өчен билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү;

5) Казан шәһәре Мэры, Башкарма комитет, Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башка органнары һәм вазифаи затлары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан расага, милләткә, телгә, дингә мөнәсәбәткә һәм башка шартларга бәйле рәвештә кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлегенең дәүләт гарантияләрен массакүләм бозу, әгәр бу милләтара һәм конфессияара татулыкны бозуга һәм милләтара (этникара) һәм конфессияара конфликтлар барлыкка килүгә китерсә, раса, милләт, тел яки дин билгеләре буенча хокукларны чикләү һәм дискриминацияләү;

6) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрнең системалы рәвештә түбәнәюе»;

17.3. 5 өлештә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 75 статьясында» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 38 статьясында» сүзләренә алмаштырырга.

18. 80 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«80 статья. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының һәм вазифаи затларының җаваплылыгы

Казан шәһәре җирле үзидарә органнары һәм вазифаи затлары 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон нигезендә, шул исәптән алар Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституция законнарын, федераль законнарны, Татарстан

Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм әлеге Уставны бозган очракта, шулай ук күрсәтелгән органнар һәм вазифаи затлар үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә башкармаган очракта, Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылык тоталар».

19. 84 статьядагы 2 өлешнең өченче абзацында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 44 статьясындагы 8 өлешнең беренче абзацы белән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законның 56 статьясындагы 9 өлеше белән» сүзләренә алмаштырырга».

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**